СОВЕТ КИЛЬДЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КИЛДИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Ул. Советская, д.7, с. Шеланга,
422577

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ | КАРАР

29.11.2019 Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48. 60-292

с. Кильдеево

Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлегенең
2020 елга һәм 2021-2022 елларның планлы чорына бюджеты проекты турында

Килди авыл җирлеге башлыгы докладын тыңлап һәм Килди авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021, 2022 елларның планлы чорына бюджет проектын карап тикшергәннән соң

Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы бюджеты проектын беренче укылышта кабул итәргә (1нче кушымта).
2. 2019 елга, 2020 һәм 2021 елларның планлы чорына Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге бюджеты проекты буенча 2019 елның 13нче декабренә, Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында 10:00 сәгатькә халык алдында тыңлаулар билгеләргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге Башлыгы В.М.Бурдин

Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге Советының
2019 елның 29 ноябрендәге
60-292нче номерлы карарына
1нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлегенең
2020 елга һәм 2021-2022 елларның планлы чорына бюджеты проекты

Статья 1
1. 2020 елга Килди авыл җирлеге (алга таба –Җирлек) бюджетының төп характеристикаларын расларга:
1) җирлек бюджеты керемнәренең гомуми күләме 3674,68 мең сум;
2) җирлек бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 3674,68 мең сум.
3) җирлек бюджеты дефициты 0 мең сум.
2. 2021, 2022 еллар план чорына җирлек бюджетының төп характеристикасын расларга:
1) 2021 елга җирлек бюджеты керемнәренең гомуми күләме 3545,20 мең сум һәм 2022 елга 3592,94 мең сум күләмендә;
2) җирлек бюджетының гомуми күләме:
- 2021 елга 3545,20 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 88,63 мең сум күләмендә;
- 2022 елга 3592,94 мең сум күләмендә, шул исәптән 179,65 мең сум шартлы рәвештә расланган чыгымнар.
3) 2021 елга җирлек бюджеты дефициты 0 мең сум һәм 2022 елга 0 мең сум күләмендә.
3. Җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын билгеләргә:
- 2020 елга әлеге карарга  1нче кушымта нигезендә;
- 2021 һәм 2022 еллар план чорына әлеге карарның 2нче кушымта нигезендә.

Статья 2
1. 2021 елның 1 гыйнварына җирлекнең бурыч йөкләмәләре буенча эчке муниципаль бурычның иң югары чиген 0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә билгеләргә.
2. 2022 елның 1 гыйнварына җирлекнең бурыч йөкләмәләре буенча эчке муниципаль бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә билгеләргә.
3. 2023 елның 1 гыйнварына җирлекнең бурыч йөкләмәләре буенча эчке муниципаль бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә билгеләргә.
4. Җирлекнең муниципаль бурычының чикле күләмен билгеләргә:
- 2020 елда – 0 мең сум күләмендә;
- 2021 елда – 0 мең сум күләмендә;
- 2022 елда – 0 мең сум күләмендә.

Статья 3
Җирлек бюджетында 2020 елга керемнәрнең фаразлана торган күләмнәрен әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә, 2021 һәм 2022 еллар план чорына әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

Статья 4
2020 елда һәм 2021 һәм 2022 елларның планлы чорында җирлек бюджетына күчерелү салымнар түләгәннән соң калган һәм башка мәҗбүри түләүләрдән калган муниципаль унитар предприятиеләр табышының бер өлешен кертү 2019, 2020 һәм 2021 елларга алынган чиста табышның 30 проценты күләмендә башкарыла дип билгеләргә.

Статья 5
1. Җирлек бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә расларга

Статья 6
1.Бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре төркемнәре буенча җирлек бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бүлүне расларга:
- 2020 елга әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә;
- 2021 һәм 2022 еллар план чорына әлеге карарга 8 нче кушымта нигезендә.
2. Күрсәтелгән чыгымнарның ведомство структурасын түбәндәгечә расларга:
- 2020 елга әлеге карарга 9 нчы кушымта нигезендә;
- 2021 һәм 2022 еллар план чорына әлеге карарга 10 нчы кушымта нигезендә.

Статья 7
Югары Ослан муниципаль районы бюджетыннан алына торган җирлек бюджетында бюджетара трансфертларны исәпкә алырга:
- 2020 елда әлеге карарга 11 нче кушымта нигезендә 2772,08 мең сум күләмендә.
- 2021 елда әлеге карарга 12 нче кушымта нигезендә 2828,90 мең сум һәм 2022 елда 2869,14 мең сум күләмендә

Статья 8
Җирлек муниципаль хакимият органнары 2020 елда һәм 2021 һәм 2022 елларның планлы чорында муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре һәм бюджет өлкәсендәге башка оешмалар хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуксыз.

Статья 9
2020 елда җирлек милкендә булган һәм бюджет мәдәният һәм сәнгать, сәламәтлек саклау, мәгариф учреждениеләренә, шулай ук архив учреждениеләренә оператив идарәгә тапшырылган мөлкәтне арендага бирүдән кергән керемнәр җирлек бюджеты керемнәре составына кертелә һәм әлеге карар нигезендә бюджет йөкләмәләрен үтәүгә файдаланыла дип билгеләргә.

Статья 10
Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә җирлек бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

Статья 11

Башкарма комитет тарафыннан тиешле карар кабул ителгән очракта, 2020 елның 1 гыйнварына җирлек исеменнән төзелгән товарларны китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү өчен түләү өчен файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмаган күләмдә 2020 елның 1 гыйнварына җирлек бюджетының калган акчалары әлеге муниципаль контрактлар шартлары нигезендә 2019 елда түләнергә тиешле хезмәтләрне күрсәтү өчен 2020 елның 1 гыйнварына күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

Статья 12
Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Статья 13
Әлеге карар Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырылырга тиеш.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге Башлыгы В.М.Бурдин